СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2023 г. Агрыз № 30-3

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 21 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын килештерү процедурасын үткәрү нәтиҗәләре буенча аларга карата генераль планнар әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителү нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга (26.10.2022 елның 20-6 номерлы карар редакциясендә).
2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
29.08. 2023 елның № 30-3 карары
белән расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы карарына (26.10.2022 елның 20-6 номерлы карар редакциясендә) үзгәрешләр**

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы карарына түбәндәге эчтәлекле 1.2 пункты өстәргә:

«1.2. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләре турында белешмәләр исемлеген расларга.» (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы карары (26.10.2022 елның 20-6 номерлы карары редакциясендә) белән расланган, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр өстәп, аларга карата «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ эшләгән генераль планнарны әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
29. 08. 2023 елның № 30-3
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләре турында белешмәләрнең өстәмә исемлеге

- Кадрәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Кадрәк авылы;
- Кадыбаш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Кадыбаш авылы, Касай авылы, Яңа Эсләк авылы;
- Иске Эсләк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Иске Эсләк авылы, Үтәгән авылы;
- Кырынды авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Кырынды авылы, Чишмә авылы, Еленовский поселогы, Тукай поселогы;
- Бима авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Пеләмеш авылы;
- Кодаш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Кыдырлы авылы;
- Күләгәш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Байтуган авылы;
- Көчек авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Варкләд-Бодья авылы;
- Яңа Бәзәкә авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Яңавыл авылы, Иске Никольский поселогы,;
- Сарсак-Умга авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Сарсак-Умга авылы, Сәрдәле авылы;
- Иске Чекалда авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Иске Чекалда авылы.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Советының 30.04.2013 елның 24-4 номерлы
карарына кушымта
(26.10.2022 елның 20-6 номерлы карар
редакциясендә)
Һәм 29.08. 2023 елның № 30-3
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә, аларга карата «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ эшләгән генераль планнарны әзерләү кирәклеге булмау турында карарлар кабул ителгән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы